КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 март г.Казань № 251

Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга дәүләт экспертизасы турында

«Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында» 2017 елның 26 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга дәүләт экспертизасы үткәрү тәртибен;

матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга дәүләт экспертизасы үткәрү буенча эксперт советы составын.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 март, 251 нче
карары белән расланды

Матди булмаган мәдәни мирас объекты
билгеләренә ия булган объектларга дәүләт экспертизасы үткәрү
тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип «Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында» 2017 елның 26 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 3 августындагы 636 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектлары реестры турындагы нигезләмә (алга таба – Реестр турындагы нигезләмә) нигезендә эшләнде һәм матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга дәүләт экспертизасы (алга таба – дәүләт экспертизасы) үткәрү процедурасын, дәүләт экспертизасы кысаларында тикшеренүләр үткәрү тәртибен, дәүләт экспертизасы үткәрүче экспертларга карата квалификация таләпләрен, шулай ук дәүләт экспертизасы өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт экспертизасы матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга карата матди булмаган мәдәни мирас объектын Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектлары реестрына (алга таба – Реестр) кертүне яки кертүдән баш тартуны йә объектны реестрдан төшереп калдыруны нигезләү максатларында үткәрелә.

1.3. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга дәүләт экспертизасы түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

объектның тарихи һәм мәдәни әһәмияте;

объектның мәдәни традицияләргә яки этник, социаль яки конфессиональ төркем мәдәнияте тарихына урнашу дәрәҗәсе;

мәдәни традициянең уникаль дәлиле буларак объектның кыйммәте;

объектның юкка чыгу куркынычы.

1.4. Дәүләт экспертизасы үткәрү максатларында, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык) Реестр турындагы нигезләмәнең 3.3 нче пункты белән билгеләнгән тәртиптә бирелгән матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларны Реестрга кертү турындагы гаризаны (алга таба – гариза) гариза кергән көннән эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга дәүләт экспертизасы үткәрү буенча эксперт советына (алга таба – эксперт советы) карауга кертә.

1.5. Гаризаны карап тикшерү вакыты Реестр турындагы нигезләмәнең 3.6 нчы пункты белән регламентлаштырыла.

## II. Эксперт советының эш тәртибе

2.1. Эксперт советы эшчәнлеге түбәндәге принципларга нигезләнә:

матди булмаган мәдәни мирас объектларының сакланышын презумпацияләүгә;

фәнни нигезлелек һәм объективлыкка;

мәгълүматның дөреслегенә һәм тулылыгына;

экспертлар советы әгъзаларының бәйсезлегенә;

хәбәрдарлыкка.

2.2. Экспертлар советы составына галимнәр, тарих, этнология һәм этнография, фольклористика, сәнгать белеме, музыка, хореография, культурология, мәдәният тарихы һәм теориясе өлкәсендәге белгечләр, мәдәният эшлеклеләре, матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклау, өйрәнү, файдалану һәм популярлаштыру өлкәсендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар, шулай ук профильле фәнни-тикшеренү, мәгариф һәм мәдәният оешмаларының квалификацияле белгечләре кертелә.

2.3. Экспертларга карата квалификация таләпләре түбәндәгеләр була:

тарих, этнология һәм этнография, фольклористика, сәнгать белеме, музыка, хореография, культурология, мәдәният тарихы һәм теориясе тармагында матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклау, өйрәнү һәм популярлаштыру өлкәсенә караган фәнни, фәнни-популяр басмалар булу;

матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклау, актуальләштерү һәм популярлаштыру өлкәсендә тикшеренү, экспозиция-күргәзмә, мәдәният-мәгариф, аң-белем тарату, мәдәни-ял итү проектларын тормышка ашыру тәҗрибәсе булу.

2.4. Эксперт советы эшен эксперт советы рәисе яраштыра.

2.5. Оештыру-техник эшчәнлекне яраштыру, утырышларны әзерләү һәм документларны алып бару өчен эксперт советы рәисе тарафыннан эксперт советының җаваплы секретаре билгеләнә.

2.6. Эксперт советы эше аның утырышларында гамәлгә ашырыла. Эксперт советы утырышы, әгәр дә анда эксперт советы әгъзаларының гомуми санынннан кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала

2.7. Эксперт советы утырышлары елга кимендә 2 тапкыр үткәрелә.

2.8. Эш нәтиҗәләре буенча эксперт советы матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектның бу Тәртипнең 1.3 нче пунктында билгеләнгән критерийларга туры килүе (туры килмәве) турында бәяләмә рәвешендәге карарны кабул итә.

2.9. Эксперт советы карары утырышта катнашучы эксперт советы әгъзалары саныннан гади күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, эксперт советы рәисе тавышы хәлиткеч була.

2.10. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектның аны Реестрга кертү яки кертүдән баш тарту йә Реестрдан төшереп

калдыру критерийларына туры килүе (туры килмәве) турындагы бәяләмә, гаризаны карап тикшерү вакыты чыкканга кадәр 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка җибәрелә.

2.11. Дәүләт экспертизасы бәяләмәләре, гаризалар, дәүләт экспертизасына һәм эксперт советы эшенә кагылышлы документлар Министрлык архивында саклана.

## III. Дәүләт экспертизасы кысаларында матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларны тикшерүләрне үткәрү тәртибе

3.1. Дәүләт экспертизасы үткәрү кысаларында эксперт советы әгъзалары тарафыннан гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар һәм дәүләт экспертизасы барышында алынган мәгълүматлар нигезендә матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларны тикшерү үткәрелә:

аудио-, видео-, фото-, текст һәм график материаллар;

тарих, традицион мәдәният, башкару сәнгате, филология, фән һәм техника, архивлар, эстетика, этнология, антропология, социаль мәдәният күзлегеннән объект турында мәгълүматы булган артефактлар.

3.2. Эксперт советы әгъзалары матди булмаган мәдәни мирас объектын Реестрга кертүнең нигезле (яки нигезсез) булуы мәсьәләсен карау максатларында фәнни, техник, сәнгати тикшеренүләрне, бу Тәртипнең 3.1 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны документлаштыруны, тәңгәлләштерүне үткәрә.

3.3. Үткәрелгән тикшеренү нигезендә эксперт советы әгъзасы матди булмаган мәдәни мирас билгеләренә ия булган объектның бу Тәртипнең 1.3 нче пунктында билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә (кимендә 4000 билге күләмендә) әзерли, аның формасы Министрлык боерыгы белән расланa.

3.4. Экспертлар советы әгъзасы бәяләмәдә түбәндәгеләрне чагылдыра:

матди булмаган мәдәни мирас объектын Реестрга кертүнең нигезле (яки нигезсез) булуын;

матди булмаган мәдәни мирас объектын Реестрдан төшереп калдыру кирәклеген;

Реестрга кертелгән матди булмаган мәдәни мирас объекты турындагы, матди булмаган мәдәни мирасның ачыкланган объекты турындагы мәгълүматларга (матди булмаган мәдәни мирас объекты исеме турында, көнкүреш һәм аның белән бәйле тарихи вакыйгалар турындагы мәгълүматларга) аныклык кертү кирәклеген;

Реестрга кертелгән матди булмаган мәдәни мирас объектлары, матди булмаган мәдәни мирасның ачыкланган объектлары йә матди булмаган мәдәни мирас билгеләренә ия булган объектлар сакланышын тәэмин итү кирәклеген.

## IV. Дәүләт экспертизасы өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе

4.1. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган бер объектка карата дәүләт экспертизасына түләү күләме дәүләт экспертизасы кысаларында матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектлар турындагы мәгълүматларны документлаштыруны, тәңгәлләштерүне

үткәрү өчен эксперт советы әгъзаларына түләү өчен җыелма чыгымнардан чыгып билгеләнә.

4.2. Дәүләт экспертизасы өчен түләү Министрлык ведомствосы буенча каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт экспертизасы өчен түләү күләме, эксперт советы әгъзаларына түләүнең җыелма күләменнән чыгып, түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_{общ} = S_1 + S_2 + \ldots + S_n ,$$

$$S_{1,\,2,\,\ldots n} = (M + K_n) \times M),$$

монда:

$S_{общ}$ – дәүләт экспертизасы өчен түләү күләме,

$S_1$ , $S_2$ , $S_n$ – эксперт советы әгъзасына түләү күләме,

М – «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләме,

$K_n$ – арттыру коэффициенты:

фәннәр кандидатының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен – 10 процент күләмендә,

фәннәр докторының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен – 20 процент күләмендә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 март, 251 нче
карары белән расланды

Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга
дәүләт экспертизасы үткәрү буенча эксперт советы
составы

| | |
|---|---|
| Җәүһәрова Фәнзилә Хәким кызы | «Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, эксперт советы рәисе |
| Габдрахманова Гөлнара Фаад кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесенең этнология бүлеге мөдире (килешү буенча) |
| Гомәров Илһам Госман улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» дәүләт бюджет учреждениесенең язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире (килешү буенча) |
| Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы | «Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең фәнни-тикшеренү бүлеге мөдире |
| Донина Лариса Николаевна | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесенең өлкән фәнни хезмәткәре (килешү буенча) |
| Каюмова Эльмира Ринат кызы | «Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең төп фәнни хезмәткәре |
| Мансурова Гөлнара Камил кызы | «Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең төп фәнни хезмәткәре |
| Мирхаев Рифат Фирдинат улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» дәүләт бюджет учреждениесендәге гомуми лингвистика бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы | «Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендәге халык иҗаты бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре |
| Пашина Ольга Алексеевна | «Дәүләт сәнгать белеме институты» федераль дәүләт бюджет фәнни-тикшеренү учреждениесе гыйльми секретаре (килешү буенча) |
| Сәрвәрева Лилия Илдүс кызы | югары белем бирүче «Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе доценты (килешү буенча) |
| Смирнова Елена Михайловна | югары белем бирүче «Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе профессоры (килешү буенча) |
| Столярова Гүзәл Рафаил кызы | югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе профессоры (килешү буенча). |